РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Масягутовского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Дружба, д. 12, Азнакаевский район,
с.Масягутово, 423321,
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге
башлыгы

Дружба ур., 12 йорт, Азнакай районы, Мәсгут
авылы, 423321
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «07» марта 2024г.** **№ 2**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлегенең Якши-Бай торак пунктында гражданнар җыенының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлегенең Якши-Бай авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы карарына, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлегенең Якши-Бай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «2024 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы карары, Мәсгут авыл җирлеге торак пунктының 25.1 Уставы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге муниципаль берәмлек Башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Якши-Бай торак пунктында:«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлегенең Якши-Бай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 24.11.2023 № 2, «2024 елда Якши-Бай торак пунктында гражданнарның үзара салым кертү турында» 24.11.2023 № 1 карарына

үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 18 мартына 13.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, 24.11.2023 №1 “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Якши-Бай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында”, 24.11.2023 №2 “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Якши-Бай торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында” гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертүгә ризамы:

- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өстендәге үтүләрне ремонтлау(Якшы-Бай торак пунктында җәяүлеләр күперен ремонтлау).

« РИЗА» «КАРШЫ».

3.Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Мәсгут авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatar.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районының Мәсгут җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция Министрлыгына җибәрергә

Халык җыенында рәислек итүче,Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге башлыгы: Д.З.Миннеханов